**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Поповка авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 25** **22.04.2021 ел**

**"2020 елда Зәй муниципаль районы**
**Поповка авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турында"**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Уставының, Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1. 2020 ел өчен Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 3221,3 тыс сум, чыгымнар буенча 3265,5 тыс сум, керемнәрне чыгымнардан 44,2 тыс. сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2020 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2020 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 3нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча 2020 ел өчен бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 4нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.А.Амерханов**